Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Советы

**КАРАР №IV-3**

Балык Бистәсе штп. 2025елның 22 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 25.05.2023 №XXXVIII-10 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 03.10.2025 ел, №66-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 25.05.2023 №XXXVIII-10 (26.09.2023 №XLII-7; 06.02.2024 №XLVI-2; 22.10.2024 №LI-5 редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Нигезләмәне түбәндәге эчтәлекле 3.2.1 пункт белән тулыландырырга:

«3.2.1. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типик квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белем булу – вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларыннан тыш; югары белем яисә урта һөнәри белем булу – авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча-кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча-муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.».

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы” нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе

муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль районы Башлыгы Р.Р. Ислямов